“АРЧА 1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”

# Чишмә башы

№ 7
Май

Әти-әниләр һәм балалар өчен татарча гәҗит

## *Исәнме ямьле җәй*

Исәнме ямьле җәй!
Сагынып көттек сине.
Яшел тугайларыңны
Аллы-гөлле чәчкәләрне,
Кояшлы көннәреңне…

Күңелле җәйләр булсын
Кояш нурларын сипсен,
Җылы яңгырлар яусын
Тормышыбыз ямьләнсен,
Уңышлар мулдан булсын!

Җәй – бик матур ел фасылы. Бу – көтеп алган жәйге ялыбыз – безнең озын эш көннәребез, көнкүреш мәшәкатьләребез өчен лаеклы бүләк. Гаилә ялы – сез үз балагызга бирә алырлык максималь вакыт. Бала өчен ул – шулай ук ел буе көтеп алынган зур вакыйга.

Җәй – балаларның сәламәтлеген ныгыту өчен иң уңайлы вакыт. Жәй көне алар аеруча хәрәкәтчән һәм шат күңеллеләр. Балалар вакытларын көне буе һавада үткәрә. Табигатьнең матурлыгы, җылы саф һава, төрле файдалы азык – боларның барысы да балалар организмына уңай йогынты ясый. Суда йөзү, велосипедта йөрү, туп белән уеннар, йөгереп йору, сикерүләр баланың сәламәтлегенә зур файда китерә. Шулай вестибуляр аппарат үсә, мускуллар ныгый, көч, тигезлек, җитезлек, чыдамлык, кыюлык үсә. Балаларнын кәефләре, күнелләре күтәрелә.

**Ә ял итү сезгә һәм сезнең балагызга ләззәт кенә китерсен өчен кайбер кагыйдәләрне үтәргә тырышыгыз:**

– әгәр дә сез үз балагыз белән шөгыльләнергә карар кылгансыз икән, бу шөгыльләр кыска булырга һәм алар иртәнге сәгатьләрдә үткәрелергә тиеш. Сезнең бурыч – баланың булган белемнәрен һәм тормыш тәҗрибәсен берләштереп, аларның дөньяга карашын киңәйтү;
– шәһәр читенә чыкканда яки дөнья буйлап сәяхәт иткәндә, бала белән алган тәэсирләр турында фикер алышырга кирәк икәнен хәтерләргә кирәк;
– барлык көчегез белән баланы телевизордан һәм компьютердан аерыгыз, буш вакытыгызны саф һавада үткәрегез, велосипедта, самокатта, роликларда йөрегез, футбол уйнагыз. Җәй – ул баланың сәламәтлеген ныгыту чоры, һәм аның киләсе уку елындагы сәламәтлеге күп яктан шушы чор белән бәйле;
-көндәлек режимны сакларга тырышыгыз. Онытмагыз: йокы җитешсезлекләре неврозлар китереп чыгара, арыганлыкны арттыра. Бала 10 сәгатьтән дә ким йокламаска тиеш.

**Якты, матур җәйге көннәрдән файдаланып калыгыз!**

## Сау бул бакча!

**Безнең балалар бакчасында чыгарылыш балы - искиткеч һәм күңелне җилкендерә торган бәйрәм узды. Балалар шатлык белән һәм бер үк вакытта алар өчен икенче йорт булган балалар бакчасы белән моңсуланып саубуллаштылар.**

**Бәйрәмдә балалар ата-аналарын һәм тәрбиячеләрне матур чыгышлар белән гаҗәпләндерделәр: биюләр, җырлар һәм шигырьләр сөйләделәр . Бәйрәм азагында барлык чыгарылыш балаларына истәлеккә дипломнар һәм бүләкләр тапшырдылар.**
**Аларга уңышлар телибез!**





# Бакчабызда Сабантуй бәйрәме

Сабантуй бәйрәме – татар халкының йөзек кашы булган зур бәйрәмнәрнең берсе. Ул – хезмәт һәм дуслык бәйрәме. Без бай тарихыбызны, тирән мәгънәле милли көйнең матурлыгын, бөек шәхесләребезнең әсәрләрен, татар халкының гореф-гадәтләрен, йолаларын күз карасыдай сакларга тиеш.

Татар халкының моңлы җырлары, дәртле биюләре, кызыклы уеннары балаларның күңелләрендә уелып калсын өчен Арчаның беренче балалар бакчасында Сабантуй бәйрәме гөрләп узды. Милли кием кигән балалар һәр төркемгә кереп сабантуй турында җырлар, шигырьләр сөйләделәр, бүләкләр җыйдылар, бәйрәмгә чакыру өләштеләр. Бәйрәм яшел үләнле мәйданчыкта үткәрелде. Бертуктаусыз милли көйләр яңгырады. Балалар аркан тартышу, капчык киеп йөгерү, кашык белән су ташу, таяк тартып көч сынашу, кашыкка йомырка салып чабу, чүлмәк вату һ.б. шундый кызыклы уеннвр уйнадылар. Һәрбер балага үзенең осталыгын күрсәтергә мөмкинчелек бирелде: кемдер җырлады, кемдер биеде, кемдер шигырь сөйләде. Бәйрәмнән бер бала да бүләксез китмәде. Бакчада оештырылган әлеге чара балаларның күңеленә бик хуш килде.







